*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2025-2026 нчы уку елы)
**4 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 90 минут**
**Максималь балл – 36**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Парсыз яңгырау тартыклардан гына торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) малай
   ә) егет
   б) диңгез
   в) тәрәзә

2. Нечкә сузык авазлардан гына торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) аваз
   ә) хәреф
   б) басым
   в) китап

3. Аваз белән хәреф саны туры килмәгән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) яфрак
   ә) агач
   б) тамыр
   в) көньяк

4. Басымы беренче иҗеккә төшкән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) зәңгәр
   ә) аларның
   б) укыдылар
   в) килмә

5. ***Киң*** сүзенең антонимын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) ерак
   ә) тар
   б) тәбәнәк
   в) якын

6. Кушма сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) эшче
   ә) кызчык

б) унике
в) көймә

7. Чыгыш килешендәге исемне билгеләгез. **(2 балл)**
а) авылга
ә) авылны
б) авылда
в) авылдан

8. Хикәя җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
а) Без чәчәкләр җыябыз.
ә) Сез чәчәкләр җыясызмы?
б) Син кайда укыйсың?
в) Туган җиреңне ярат!

## II. Теоретик бирем.

Төшеп калган авазны һәм сүзләрне языгыз. **(4 балл)**
[ә] – нечкә _________________ аваз. В хәрефе [в] һәм [ ___ ] авазларын белдерә. -ның/-нең _____________ килеше кушымчасы. Мин, син, ул, без, сез, алар – _____________ алмашлыклары.

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Сүзләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(4 балл)**

*пуговица* – ___________ *хвост* – ___________
*куст* – ___________ *урожай* – ___________

2. Сез җәйге каникулны ничек үткәрдегез? Шул хакта 6 җөмлә төзеп языгыз. **(12 балл)**